Тукай муниципаль районы
Күзкәй авыл җирлеге
Күзкәй авылы
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«08» ноябрь 2025 ел № 2

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “Күзкәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Советы Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда граждannар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында 2019 елның 05 ноябрендәге 10/1 номерлы карары нигезендә Күзкәй авылы җирлеге Күзкәй авылы граждannар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. «Күзкәй авыл җирлегенең Күзкәй авылы территориясендә 2026 елда балигъ булган, Күзкәй авыл җирлегенең Күзкәй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә, I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт граждannарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә, аны әлеге категория граждannар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган граждannарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Күзкәй авылының Пионер һәм Муса Җәлил урамнары буенча юлларны ремонтлау).

2. Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Күзкәй авылы граждannар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Күзкәй авылы граждannар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Граждannар җыенында рәислек итүче,
Күзкәй авыл җирлеге Башлыгы Э.Р. Гәрәев